Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге Советының кырык икенче утырышы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге Советы
КАРАЫ

19 ноябрь, 2024 ел № 115

Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге торак пунктлары территориясе өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җыеннар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге уставының 23 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы 2019 елның 08 ноябрендәге 54 номерлы (2021 елның 17 декабрендәге 35 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән) Шигали авыл җирлеге Советы карары, имзалар кәгазьләре нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Шигали авыл җирлегенең торак пунктлары территориясенең бер өлешендә түбәндәге торак пунктларда гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.1. Яңа Шигали авылы Дан, Гаврилов, Ватан урамнары гражданнары өчен 2024 елның 19 октябрендә 17.00 сәгатьтә Дан урамында гражданнар җыенын үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2025 елда Шигали авыл җирлеге Яңа Шигали авылы Дан, Гаврилов, Ватан урамнары территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 5000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- торак пункт (Дан ур.) чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Шигали авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге башлыгы В.М. Сәлимов